**Карар**
**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге**
**Карман торак пунктында гражданнар җыены карары**

**12.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең **Карман** торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Бигеш авыл җирлегенең **Карман** торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын, белем бирүнең көндезге формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- чишмә территориясен төзекләндерү;
- парк зонасы территориясен төзекләндерү.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бигеш авыл җирлеге башлыгы ____________________ И.Р. Вәлиев
(имза) (имза расшифровкасы)